ПРОЕКТ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ШИЛЬНЕБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«15» августа 2019 ел Шильнебаш авылы № 36/4

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2017 елның 13 апрелендәге «Җирлекләр, шәһәр округлары, шәһәр эче районнары территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик тәкъдимнәрне раслау турында» 711/пр санлы приказы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлеге уставы нигезендә Шильнебаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Муниципаль берәмлекнең 2012 елның 15 октябрендәге 15/1 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Әлеге кагыйдәләрнең 1 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

**«2. Төп төшенчәләр**

Әлеге кагыйдәләрдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

**арборицидлар** – чүп агач-куак үсемлекләренә каршы кулланыла торган химик матдәләр;

**территорияне төзекләндерү** – муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру буенча, гражданнарның яшәү шартларын тәэмин итүгә һәм уңайлылыгына, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын яхшыртуга, торак пунктлар территорияләрен, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, якын-тирә территорияләрне карап тотуга юнәлдерелгән эшчәнлек.»;

**Сосновский балтырганы** – чатырлылар гаиләлегенә кергән эре үлән үсемлеге. Үсемлек тән тиресен пешереп, озак төзәлми торган яралар ясый;

**ташландык транспорт чарасы** – милекче тарафыннан алты айга һәм аннан да күбрәк срокка калдырылган, башка затларның аңа керү мөмкинлеге (ишекләр, кузовның пыяла, башка элементлары булмау, ишекләре ачык булу, ишекләрне

бикләү мөмкинлеге булмау аркасында һ.б.) чикләнмәгән, шулай ук аны билгеләнеше буенча куллану мөмкин булмаган (көпчәкләре тишек булу, тәгәрмәчләре яки башка конструктив детальләре булмау һ.б.) һәм транспорт чараларын саклау өчен билгеләнмәгән (транспорт чараларын урнаштыру өчен махсус билгеләнгән урыннардан тыш) гомуми файдаланудагы урыннарда (йорт яны территорияләрендә) яки озак вакыт (алты ай һәм аннан күбрәк) транспорт чараларын урнаштыру өчен махсус билгеләнгән урыннарда (парковка, парковка урыннарында, түләүле автостоянкаларда, гаражлардан яки техниканы саклау өчен билгеләнгән башка биналардан тыш) торган һәм машиналар, җәяүлеләр йөрешенә, территорияне җыештыруга, ашыгыч хезмәт автомашиналары, башка махсус транспортның йөрешенә, чүп җыю машиналарының подъездлар, чүп контейнерлары янына керүенә киртә булып торган һәм (яки) авыл җирлеге (шәһәр округы) территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен бозып урнаштырылган транспорт чарасы. Ташландык транспорт чарасы, машиналар, җәяүлеләр йөрешенә, территорияне җыештыруга, ашыгыч хезмәт автомашиналары, башка махсус транспортның йөрешенә, чүп җыю машиналарының подъездлар, чүп контейнерлары янына керүенә комачауламау, шулай ук потенциаль терроризм куркынычын бетерү максатында билгеләнгән тәртиптә эвакуацияләнергә тиеш;

**төзекләндерү элементларының нормалаштырыла торган комплексы** – муниципаль берәмлек территориясендә куркынычсыз, уңайлы һәм җәлеп итүчән мохит булдыру өчен төзекләндерү элементларының минималь ярашуы;

Төзекләндерү элементларының нормалаштырыла торган комплексы җирле нормалар һәм территорияне төзекләндерү кагыйдәләре составында җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә.

**территорияне төзекләндерү объектлары** – төзекләндерү буенча эшчәнлек алып барыла торган муниципаль берәмлек территорияләре: мәйданчыклар, ишегаллары, кварталлар, функциональ-планлаштыру районнары, административ округлар һәм шәһәр округлары районнары территорияләре, шулай ук бердәм шәһәр төзелеше регламенты (саклау зоналары) яки визуаль-пространство аша кабул итү принцибы (төзелеш белән мәйдан, якын-тирә территория һәм төзелеш белән урам) буенча бүленә торган территорияләр, муниципаль берәмлекнең башка территорияләре;

**территорияләрне төзекләндерүне нормалаштыру объектлары** – территорияне төзекләндерү буенча нормаларда һәм кагыйдәләрдә түбәндәгеләр билгеләнә торган муниципаль берәмлек территорияләре: төзекләндерү элементларының нормалаштырыла торган комплексы, аларны әлеге территориядә урнаштыру нормалары һәм кагыйдәләре. Түбәндәгеләр мондый территорияләргә керергә мөмкин: төрле функциональ билгеләнештәге мәйданчыклар, җәяүлеләр коммуникацияләре, юллар, җәмәгать киңлекләре, җәмәгать, торак төзелеше урыннары һәм зоналары, производство төзелешенең санитар-сак зоналары, рекреация объектлары, торак пунктның урам-юл челтәре, инженерлык коммуникацияләренең техник (саклау-эксплуатация) зоналары;

**территорияләрне җыештыру** – җитештерү һәм куллану калдыкларын, башка чүп-чарны, карны җыю, махсус билгеләнгән урыннарга чыгару белән бәйле эшчәнлек төре, шулай ук халыкның экологик һәм санитар-эпидемиологик

иминлеген тәэмин итүгә һәм әйләнә-тирә мохитне саклауга юнәлтелгән башка чаралар;

**яшелләндерү** – үсемлекләр компонентларыннан актив файдаланып, муниципаль берәмлек мохитен формалаштыруны тәэмин итүче территорияне төзекләндерү һәм ландшафтлы оештыру, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә элегрәк барлыкка килгән яки башта булган табигый тирәлекне саклау элементы;

**туплаучы бункер** – күләме 2,0 куб метрдан артык, эре габаритлы калдыклар җыю өчен стандарт савыт;

**каты коммуналь калдыклар** – физик затлар куллану процессында торак урыннарда барлыкка килгән калдыклар, шулай ук физик затлар тарафыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында торак биналарда файдалану процессында үз куллану үзенчәлекләрен югалткан товарлар. Каты коммуналь калдыкларга шулай ук юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган һәм физик затлар куллану процессында торак биналарда барлыкка килүче калдыкларның составына охшаш калдыклар керә;

**сыек көнкүреш калдыклары** – халыкның тормыш эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килүче калдыклар (азык әзерләү, торак биналарны җыештыру, үзәкләштерелмәгән канализациянең фекаль калдыклары һ.б.);

**каты коммуналь калдыкларны чыгару** – каты коммуналь калдыкларны җыелган урыннарыннан каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү өчен файдаланыла торган объектларга кадәр ташу;

**сыек көнкүреш калдыкларын чыгару** – үзәкләштерелмәгән канализация объектларыннан лицензияләнгән чистарту объектына (чистарту корылмаларына) сыек көнкүреш калдыкларын махсус транспорт белән төяү һәм китерү;

**гербицидлар** – үсемлекләрне юк итү өчен кулланыла торган химик матдәләр;

**каты коммуналь калдыкларны, сыек көнкүреш калдыкларын чыгару графигы** – каты һәм сыек көнкүреш калдыкларын чыгаруга килешүнең урыны (адресы), калдыкларның күләме һәм чыгару вакыты күрсәтелгән состав өлеше;

**йорт биләмәсе** – аның янәшәсендәге җир кишәрлеге белән шәхси торак йорт;

**яшел утыртмалар** – аерым территориядә урнашкан агач, куак һәм үлән үсемлекләре җыелмасы;

**җир эшләре** – шәһәр территориясенең камилләштерелгән яки грунт өслеген бозып яки юллар һәм тротуарларның камилләштерелгән өлекләрен урнаштырып (җәеп) грунтны алу, урнаштыру белән бәйле эшләр;

**зур габаритлы калдыклар** – күләме аларны контейнерларга урнаштырырга мөмкинлек бирми торган каты коммуналь калдыклар (мебель, көнкүреш техникасы, торак биналарны агымдагы ремонтлаудан калдыклар һ. б.);

**контейнер** – эре габаритлы калдыклардан тыш, каты коммуналь калдыкларны туплау өчен билгеләнгән чүп-чар җыю савыты;

**кече архитектура формалары** – җирлек дизайны объектлары (чүп савытлары, эскәмияләр, декоратив коймалар, яктырткычлар, декоратив диварлар, фонтаннар, беседкалар, чәчәкләр өчен вазалар, монументаль-декоратив композицияләр, декоратив скульптуралар, балалар, спорт мәйданчыклары, ял мәйданчыклары җиһазлары һ.б.);

**вак ишегалды корылмалары** – җир кишәрлегендә төзелә торган вакытлы корылмалар (базлар, күгәрчен кетәкләре, сарайлар һ. б.);

**күпфатирлы торак йорт** – торак йорт янындагы җир кишәрлегенә яки мондый йортта гомуми файдаланудагы биналарга мөстәкыйль чыгу урыны булган, ике һәм аннан күбрәк фатир җыелмасы. Күпфатирлы йортта торак законнары нигезендә биналар милекчеләренең гомуми мөлкәте элементлары бар;

**чүп-чар өеме** – контейнер мәйданчыгында яки теләсә кайсы башка территориядә үз белдеге белән ташлау нәтиҗәсендә барлыкка килгән каты һәм зур габаритлы көнкүреш калдыкларының 1 куб. метрдан артмаган күләмдә җыелуы;

**рөхсәтсез чүп-чар ташлау урыны** – каты һәм зур габаритлы көнкүреш калдыкларын, җитештерү калдыкларын, юридик һәм физик затлар эшчәнлеге процессында барлыкка килгән башка чүп-чарны үз белдеге белән (рөхсәтсез) 50 кв. метрдан артык мәйданда һәм 30 куб. метрдан артык күләмдә ташлау (урнаштыру) яки җыю;

**җитештерү һәм куллану калдыклары (алга таба – калдыклар)** – җитештерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү процессында яки куллану процессында барлыкка килгән, 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ санлы «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль закон нигезендә бетерелергә тиешле матдәләр яки предметлар;

**авыл хуҗалыгы калдыклары** – авыл хуҗалыгы культураларын үстергәндә һәм авыл хуҗалыгы терлекләрен тотканда шәхси хуҗалык алып бару процессында барлыкка килә торган калдыклар (тирес, салам, чабылган үлән, чүп үләннәре, сабак һ.б.);

**территорияләрне яшелләндерү** – табигый үсемлекләр, ясалма төзелгән бакча-парк комплекслары һәм объектлары, бульварлар, скверлар, газоннар, чәчәклекләр урнаштырылган җәмәгать урыннары, торак, иҗтимагый, эшлекле, коммуналь, җитештерү өчен билгеләнешендәге аз төзелгән территория.

**чүп-чар өеме чыганагы** – үз белдеге белән ташлау нәтиҗәсендә 50 кв. метрдан артык мәйданда һәм 30 куб. метрдан артык күләмдә каты һәм зур габаритлы көнкүреш калдыклары җыелмасы;

**төзелеш объекты паспорты** – объект исеме, төзүченең (заказчының), эшләрне башкаручының (подрядчы, генподрядчы) исеме, объект буенча эшләр башкаручының фамилиясе, вазыйфасы һәм телефон номерлары, эшләрне башлау һәм тәмамлау сроклары, объект схемасы күрсәтелгән мәгълүмат тактасы;

**җир асты инженерлык коммуникацияләре** – төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр һәм кабельләр (суүткәргеч, канализация, җылылык, элемтә һ. б.);

**су басу** – елгаларда, сусаклагычларда су арту белән бәйле рәвештә грунт сулары күтәрелү, атмосфера явым-төшемнәре төшү, кар эрү, юлларга, тротуарларга асфальт-бетонны сыйфатсыз җәю, инженерлык системаларыннан һәм коммуникацияләреннән су китү яки агу, су кабул итү җайланмалары һәм өслек суүткәргеч корылмалары төзек булмау яисә хезмәт күрсәтү кагыйдәләрен бозу нәтиҗәсендә, юл участогын, транспорт тоннельләрен, территория өлешен җәяүлеләр, автотранспорт, шәһәр пассажир транспорты хәрәкәтенә тоткарлык тудыручы су басу.

Мәйданы 2 кв. метрдан артык булган, 3 сантиметрдан артык тирәнлектә су белән тулган территория су басылган дип санала;

**каты көнкүреш калдыклары полигоннары** – халыкның санитар-эпидемиологик куркынычсызлыгын гарантияли торган каты көнкүреш калдыкларын изоляцияләү һәм зарарсызландыру өчен билгеләнгән махсус корылмалар;

**муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре** – муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру буенча, гражданнарның яшәү шартларын тәэмин итүгә һәм уңайлылыгына, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын яхшыртуга, торак пунктлар территорияләрен, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, якын-тирә территорияләрне карап тотуга юнәлдерелгән эшчәнлек;

**йорт яны территориясе** – яшелләндерү элементлары, җәяүлеләрнең керү юллары, йортка керү юллары, әлеге йортта яшәүчеләр өчен мәйданчыклар (балалар, спорт, ял өчен, контейнерлар өчен, этләрне урамда йөртү өчен) һәм йортны эксплуатацияләү, хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү өчен билгеләнгән башка объектларны үз эченә алган күпфатирлы торак бина янындагы җир кишәрлеге;

**янәшә территория** – бина, корылма, койма, төзелеш мәйданчыгының, сәүдә, реклама объектларының һәм юридик яки физик затларның милегендә, биләвендә, файдалануында булган башка объектларның чикләренә турыдан-туры тоташып китүче территория;

**каты көнкүреш калдыклары җыю** – эшчеләр тарафыннан чүп-чар камераларын комплекслы җыештыру, контейнерларны тутыру һәм контейнер мәйданчыкларын чистарту белән бәйле чаралар комплексы;

**кар ташлау урыны** – кар өю өчен махсус урын;

**территорияләрне карап тоту** – биналар, төзелмәләр һәм корылмалар фасадларын, кече архитектура формаларын, койма һәм киртәләрне, төзелеш мәйданчыкларын, яшел утыртмаларны, җир асты инженерлык коммуникацияләрен һәм аларның конструктив элементларын, җир кишәрлегендә урнашкан транспорт инфраструктурасы объектларын вакытында ремонтлау һәм карап тоту белән бәйле чаралар комплексы;

**гомуми файдаланудагы юлларны карап тоту** – юлның, юл корылмаларының, юлларны комплекслы төзекләндерү элементларының транспорт-эксплуатация торышы тәэмин ителгән эшләр комплексы;

**калдыкларны сортларга аеру** – җитештерү һәм куллану калдыкларын сыйфат ягыннан аерыла торган билгеле бер критерийлар нигезендә бүлү һәм (яки) катнаштыру;

**транспорт чараларын урнаштыру өчен махсус урыннар** – закон нигезендә оештырылган автомобиль кую урыннары, гаражлар, ремонт остаханәләре һәм техниканы саклау (хезмәт күрсәтү) өчен билгеләнгән башка биналар; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юл хәрәкәте кагыйдәләре турында» 1993 елның 23 октябрендәге 1090 нчы карары белән расланган Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән парковкалар (парковка урыннары);

**каты көнкүреш калдыкларын чыгару графигын өзү** – каты көнкүреш калдыкларын чыгаруның маршрут, сәгать буенча графигын 2 сәгатьтән артыкка бозу;

**төзелеш калдыклары** – төзелеш, капиталь ремонт, ремонт, объектларны (торак биналар, биналар, корылмалар) төзекләндерү, реконструкцияләү процессында барлыкка килә торган калдыклар (такталар, кирпеч, бетон, буяу, пыяла һ. б.);

**беркетелгән территорияләрне җыештыру** – ачык грунт территорияләрен һәм территорияләрне каткан пычрактан, чүп-чардан, кардан һәм боздан, газоннарны чүптән даими чистартуга, шулай ук моның өчен махсус билгеләнгән урынга җитештерү һәм куллану калдыкларын, яфракларны, башка чүп-чарны, карны, бозны җыю һәм чыгару белән бәйле чаралар комплексы, халыкның экологик һәм санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итүгә юнәлтелгән башка чаралар;

**территорияне төзекләндерү элементлары** – төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, үсемлек компонентлары, җиһазлар һәм бизәлешләрнең төрле төрләре, кече архитектура формалары, капиталь булмаган стационар булмаган корылмалар, тышкы реклама һәм мәгълүмат.»;

2) 7.3 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«- чүп үләнен вакыт-вакыт чаптырырга, чүп үләнен һәм куак үсемлекләрен, барыннан да элек гражданнарның гомере һәм сәламәтлеге өчен куркыныч тудыручы үсемлекне – Сосновский балтырганын юк итәргә.

Сосновский балтырганын һәм гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч тудыручы башка үсемлекләрне бетерү чаралары чәчәк бөреләре барлыкка килгәнче һәм чәчәк ата башлаганчы үткәрелергә тиеш.

Сосновский балтырганын бетерү буенча чаралар түбәндәге ысуллар белән үткәрелә: химик – үсү учакларына гербицидлар һәм (яки) арборицидлар сиптерү, механик – коры үсемлекләрне чабу, җыю, тамыр системасын казып алу, агртехник – туфрак эшкәртү, күпьеллык үләннәр чәчү.»;

3) 9.11 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«9.11. Яшел утыртмаларны саклау, гамәлдәге кагыйдәләр нигезендә дөрес һәм үз вакытында карау, шулай ук чүп үләне һәм куак үсемлекләрен, барыннан да элек гражданнарның тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне, шул исәптән Сосновский балтырганын юк итү өчен аларныкы булган территорияләрдә предприятиеләр, оешмалар, гражданнар җаваплы.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе О.А. Гончарова

ШИЛЬНЕБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ ... ОГРН 1021601373826 р 05-11789/09 Совет ШИЛЬНЕБАШСКОГО сельского поселения ИНН 1639009866